МИНИСТЕРСТВО НАУКИ И ВЫСШЕГО ОБРАЗОВАНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
Федеральное государственное автономное образовательное учреждение
высшего образования
"Казанский (Приволжский) федеральный университет"
Высшая школа национальной культуры и образования им. Габдуллы Тукая

**УТВЕРЖДАЮ**
Проректор
по образовательной деятельности КФУ
Проф. Таюрский Д.А.
____________________________
"___"______________20___ г.

# Программа дисциплины

Современный татарский язык: Синтаксис (в татарском языке) Б1.В.ОД.7.6

Направление подготовки: 44.03.05 - Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)
Профиль подготовки: Родной (татарский) язык и литература и иностранный язык (английский)
Квалификация выпускника: бакалавр
Форма обучения: очное
Язык обучения: русский

**Автор(ы):**
Мирзагитов Р.Х. , Сагдиева Р.К.
**Рецензент(ы):**
-

**СОГЛАСОВАНО:**
Заведующий(ая) кафедрой: Галиуллина Г. Р.
Протокол заседания кафедры No ___ от "____" ___________ 201__г
Учебно-методическая комиссия Института филологии и межкультурной коммуникации (Высшая школа национальной культуры и образования им. Габдуллы Тукая):
Протокол заседания УМК No ____ от "____" ___________ 201__г

Регистрационный No

Казань
2019


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

## Содержание

1. Цели освоения дисциплины

2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы

3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля

4. Структура и содержание дисциплины/ модуля

5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения

6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов

7. Литература

8. Интернет-ресурсы

9. Материально-техническое обеспечение дисциплины/модуля согласно утвержденному учебному плану

Программу дисциплины разработал(а)(и) декан факультета института Мирзагитов Р.Х. Высшая школа национальной культуры и образования им. Габдуллы Тукая Институт филологии и межкультурной коммуникации , Ramil.Mirzagitov@kpfu.ru ; доцент, к.н. (доцент) Сагдиева Р.К. кафедра татарского языкознания Высшая школа национальной культуры и образования им. Габдуллы Тукая , Ramilya.Sagdieva@kpfu.ru

## 1. Цели освоения дисциплины

Основной целью освоения дисциплины "Синтаксис современного татарского языка" является дать целостное представление о научном освещении синтаксического строя татарского литературного языка на современном этапе его развития.

"Синтаксис" завершает курс "Современный татарский язык". Одна из главных задач его преподавания - ввести студента в современную синтаксическую проблематику, актуализируя все общеграмматические знания, приобретенные в изучении предшествующих дисциплин - морфемики, словообразования и морфологии. Замысел провести единую линию сквозь все грамматические разделы курса должен получить здесь свое завершение. Главный ожидаемый при этом "конечный результат" - умение анализировать любой татарский текст, определяя его грамматическую устроенность "снизу доверху" - от морфемики до структуры текста

## 2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы высшего профессионального образования

Данная учебная дисциплина включена в раздел "Б1.В.ОД.7 Дисциплины (модули)" основной образовательной программы 44.03.05 Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки) и относится к обязательным дисциплинам. Осваивается на 4, 5 курсах, 8, 9 семестры.

Данная учебная дисциплина входит в раздел Б.3.2/1.3.5 ФГОС по направлению подготовки ВПО 050100.62- "Педагогическое образование". Модуль Б.3.2/1."Теория языка"";

Дисциплина занимает важное место в системе курсов, ориентированных на изучение основного языка, дает совокупность теоретических и практических знаний об основных единицах этого уровня языка - словосочетание, предложение, текст и их особенностях по сравнению с другими единицами.

Синтаксис имеет одно явное преимущество перед другими разделами грамматики: он демонстрирует "язык в действии", тогда как предыдущие позволяют увидеть его "в разобранном виде" - в виде системы элементов, которые содержат лишь потенциальную информацию о своем использовании. Имея дело с готовыми для общения единицами, синтаксис уже поэтому более функционален, чем та же морфология. Это обстоятельство с тем большей настойчивостью диктует функциональный поворот в его преподавании.

Современная синтаксическая наука представлена, по существу, тремя синтаксисами: формальным, семантическим и актуальным. Приоритет формального объясняется традициями преподавания и ведения исследований, а не его "первенством" в синтаксическом механизме языка. Функциональный поворот в преподавании предполагает отказ от приоритета формального синтаксиса и, соответственно, выдвижение на первый план двух других - тех, которые "обслуживаются" формальным. Иначе говоря, можно поставить вопрос так: сначала систематизировать синтаксические средства, а потом узнать, чему они служат; а можно иначе - сначала познакомиться с теми содержательными сущностями, которые подлежат обслуживанию, а затем систематически обозреть средства, которые это делают.

Форма отчетности - экзамен в 9 семестре.

## 3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля

В результате освоения дисциплины формируются следующие компетенции:

| Шифр компетенции | Расшифровка приобретаемой компетенции |
|---|---|
| ОК-1 (общекультурные компетенции) | владеет культурной мышления, способен к обобщению, анализу, восприятию информации, постановке цели и выбору путей её достижения |
| ОК-14 (общекультурные компетенции) | готов к толерантному восприятию социальных и культурных различий, уважительному и бережному отношению к историческому наследию и культурным традициям |
| ОК-3 (общекультурные компетенции) | способен понимать значение культуры как формы человеческого существования и руководствоваться в своей деятельности и руководствоваться в своей деятельности современными принципами толерантности, диалога и сотрудничества |
| ОК-6 (общекультурные компетенции) | способен логически верно, аргументированно и ясно строить устную и письменную речь |
| ОПК-3 (профессиональные компетенции) | владеет основными речевой профессиональной культуры |
| ОПК-6 (профессиональные компетенции) | способен к подготовке и редактированию текстов профессионального и социально значимого содержания |
| СКР-1 | способен к диахроническому осмыслению и синхронному анализу языковых явлений с целью понимания механизмов функционирования и тенденций развития татарского языка |
| СКР-2 | способен выделять и анализировать единицы различных уровней языковой системы в единстве их содержания, формы и функций |
| СКР-3 | владеет основными понятиями о функциях языка, соотношении языка и мышления, роли языка в обществе, языковых универсалиях и законах развития языка |
| СКР-4 | способен определять связи татарского языка и его типологические соотношения с другими языками |
| СКР-5 | способен ориентироваться в дискуссионных вопросах языкознания и этапах его развития |
| СКР-6 | владеет приемами анализа текстов различных видов и жанров |
| СКР-7 | способен к толерантному общению в полиэтнической и поликультурной среде |

В результате освоения дисциплины студент:

1. должен знать:

- закономерности развития синтаксического строя татарского языка;
- об истории изучения предмета; о разных направлениях в синтаксисе; о синтаксических единицах; о грамматическом, синтагматическом, актуальном членении предложения;

2. должен уметь:

- обьяснять и различать синтаксические явления, изученные на лекционных и практических занятиях.
- пользоваться навыкамии полного синтаксического анализа простого, сложного, многокомпонентного предложения и текста, грамотного письма (пунктуация).

3. должен владеть:


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

- основными методами и приемами исследовательской и практической работы в области языкознания;

базовым терминологическим инструментарием современной науки о языке;

- навыками работы с необходимой информацией в глобальных компьютерных сетях;
- навыками подготовки научных работ и репрезентацией собственных научных исследований

4. должен демонстрировать способность и готовность:

- к практическому применению полученных знаний при решении профессиональных задач;
- к устной и письменной коммуникации

### 4. Структура и содержание дисциплины/ модуля

Общая трудоемкость дисциплины составляет 3 зачетных(ые) единиц(ы) 108 часа(ов).

Форма промежуточного контроля дисциплины: отсутствует в 8 семестре; экзамен в 9 семестре.

Суммарно по дисциплине можно получить 100 баллов, из них текущая работа оценивается в 50 баллов, итоговая форма контроля - в 50 баллов. Минимальное количество для допуска к зачету 28 баллов.

86 баллов и более - "отлично" (отл.);

71-85 баллов - "хорошо" (хор.);

55-70 баллов - "удовлетворительно" (удов.);

54 балла и менее - "неудовлетворительно" (неуд.).

### 4.1 Структура и содержание аудиторной работы по дисциплине/ модулю

**Тематический план дисциплины/модуля**

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практические занятия | Лабораторные работы | |
| 1. | Тема 1. Сөйләм төзелеше закончалыкларын өйрәнүче фән буларак синтаксис. Синтаксик берәмлекләр: сүзтезмә, җөмлә кисәге, җөмлә һәм текст. Интонация. | 8 | 1 | 1 | 1 | 0 | |
| 2. | Тема 2. Җөмләгә билгеләмә. Җөмләнең төп үзенчәлекләре хәбәрлек һәм модальлек. Аларның белдерелүе. Җөмләләрне төркемләү принциплары. | 8 | 2 | 1 | 2 | 0 | |

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практические занятия | Лабораторные работы | |
| 3. | Тема 3. Сүзләрнең синтаксик бәйләнеше. Сөйләмне оештыручы төп бәйленеш буларак иярткүле бәйленеш. Сүзтезмә. | 8 | 3 | 2 | 2 | 0 | |
| 4. | Тема 4. Җөмләнең баш кисәкләре. Баш кисәкләрнең хәбәрлек оештырулары. Ия. Аның төп билгеләре. Хәбәр. Исем хәбәрләр. Фигыль хәбәрләр. Гади һәм тезмә фигыль хәбәрләр. Кушма фигыль хәбәрәр. | 8 | 4 | 2 | 2 | 0 | |
| 5. | Тема 5. Иярчен кисәкләр. Иярчен кисәкләрне өйрәнү тарихы.Аергыч. Тәмамлык, аның төрләре. Хәл, аның төрләре. Аныклагыч. Модаль кисәкләр. | 8 | 5 | 2 | 2 | 0 | |
| 6. | Тема 6. Тиңдәш кисәкләр. Җөмләнең синтагмаларга бүленеше. Аерымланган кисәкләр. Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше. Сүз тәртибе. Өстәлмәләр. | 8 | 6 | 1 | 2 | 0 | |
| 7. | Тема 7. Җөмлә төрләре. Раслау һәм инкяр җөмләләр. Хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр. Тулы һәм ким җөмләләр. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр. Ике һәм бер составлы җөмләләр. | 8 | 7 | 2 | 2 | 0 | |

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практические занятия | Лабораторные работы | |
| 8. | Тема 8. Кушма җөмлә. Тезмә кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә үзенчәлекләре. | 8 | 8 | 1 | 1 | 0 | |
| 9. | Тема 9. Иярчен җөмләләрнең төзелеш һәм мәгънә ягыннан төрләре. аларның синонимлыгы. | 9 | 1 | 4 | 4 | 0 | |
| 10. | Тема 10. Катлаулы кушма җөмлә төрләре: күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә, катнаш кушма җөмлә. | 9 | 2 | 4 | 4 | 0 | |
| 11. | Тема 11. Текст. Пунктуация. | 9 | 3 | 4 | 4 | 0 | |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 9 | | 0 | 0 | 0 | Экзамен |
| | Итого | | | 24 | 26 | 0 | |

### 4.2 Содержание дисциплины

**Тема 1. Сөйләм төзелеше закончалыкларын өйрәнүче фән буларак синтаксис. Синтаксик берәмлекләр: сүзтезмә, җөмлә кисәге, җөмлә һәм текст. Интонация.**

***лекционное занятие (1 часа(ов)):***

Сөйләм төзелеше закончалыкларын өйрәнүче фән буларак синтаксис. Аның предметы, эчтәлеге, тикшеренү методлары. Синтаксис һәм логика фәннәре арасында, сөйләм һәм фикерләү арасында мөнәсәбәт. Сөйләм һәм фикерләүнең төп берәмлекләре буларак җөмлә һәм хөкем. Җөмлә кисәкләре һәм хөкем кисәкләре арасында мөнәсәбәт: субъект, предикат, бәяләү, объект, атрибут: ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәл, аныклагыч төшенчәләре. Субъект белән ия, үтәүче белән предикат, хәбәр белән процесс арасында мөнәсәбәт. Сөйләм, фикер, чынбарлык, сөйләүче, тыңлаучы төшенчәләренә аңлатма. Сөйләмнең төп үзенчәлекләре: хәбәрлек һәм модальлек. Интонация.

***практическое занятие (1 часа(ов)):***

Синтаксисның предметын, тикшеренү методларын кабатлау. Җөмлә һәм хөкем кисәкләре арасындагы мөнәсәбәтне искә төшерү. сөйләм, фикер, чынбарлык, сөйләүче, тыңлаучы төшенчәләренә аңлатма бирергә өйрәнү. Хәбәрлек һәм модальлек үзенчәлекләре.

**Тема 2. Җөмләгә билгеләмә. Җөмләнең төп үзенчәлекләре хәбәрлек һәм модальлек. Аларньң белдерелүе. Җөмләләрне төркемләү принциплары.**

***лекционное занятие (1 часа(ов)):***

Җөмләгә билгеләмә. Җөмләнең төп үзенчәлекләре хәбәрлек һәм модальлек. Аларның белдерелүе. Җөмләләрне төркемләү принциплары: грамматик кисәкләргә таркала алуы, алмавы; хикәя, сорау, боеру, тойгылы; гади, кушма; җәенке, җыйнак; бер составлы, ике составлы; тулы, ким; раслау, инкарь

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Җөмләгә билгеләмә бирү тәртибе. Гади һәм кушма җөмләне аеру, хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләрнең кулланылышы. Бер составлы, ике составлы; җыйнак, җәенке; тулы, ким; раслау, инкарь җөмләләргә кыскача күзәтү ясау.

**Тема 3. Сүзләрнең синтаксик бәйләнеше. Сөйләмне оештыручы төп бәйленеш буларак ияртүле бәйленеш. Сүзтезмә.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Сүзләрнең синтаксик бәйләнеше. Сөйләмне оештыручы төп бәйләнеш буларак ияртүле бәйләнеш. Ияртүле бәйләнешнең нәтиҗәсе буларак тезүле бәйләнеш. Тезүле бәйләнешне белдерә торган чаралар. Ияртүле бәйләнештәге сүзләр арасында мөнәсәбәт. Җөмлә барлыкка китерүче бәйләнеш буларак хәбәрлекле мөнәсәбәт. Җөмләне җәенкеләндерүче бәйләнеш буларак ачыклаулы (төгәлләүле) мөнәсәбәт һәм аныклаулы мөнәсәбәт. Аларны белдерә торган чаралар. Ияртүле бәйләнешнең традицион бүленеше: ярашу, башкарылу, янәшәлек. Сүзтезмә.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Җөмлә эченнән ияртүле һәм тезүле бәйләнешне аеру. Хәбәрлекле, ачыклаулы һәм аныклаулы мөнәсәбәттә торган синтаксик берәмлекләрне билгеләргә өйрәнү. Сүзтезмәгә анализ ясарга өйрәнү.

**Тема 4. Җөмләнең баш кисәкләре. Баш кисәкләрнең хәбәрлек оештырулары. Ия. Аның төп билгеләре. Хәбәр. Исем хәбәрләр. Фигыль хәбәрләр. Гади һәм тезмә фигыль хәбәрләр. Кушма фигыль хәбәрәр.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Җөмләнең баш кисәкләре. Җөмләнең логик-грамматик кисәкләргә бүленеше. Сүзләр төрләнешеннән чыгып, җөмләдә беренче, икенче, өченче дәрәҗәдәге кисәкләрне билгеләү. Җөмләнең баш, иярчен, модаль кисәкләргә бүленеше. Баш кисәкләрнең хәбәрлек оештырулары. Ия. Аның төп билгеләре. Төзелеше ягыннан төрләре: гади, тезмә ияләр. Иянең белдерелүе һәм төп мәгънәләре. Хәбәр.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Җөмләдән баш кисәкләрне билгеләү. Ияне табу, аның гади һәм тезмә төрләрен дөрес итеп билгели белү. Исем һәм фигыль хәбәрләрне аерырга өйрәнү. Гади, тезмә һәм кушма исем хәбәрләрне бер-берсеннән аерырга өйрәнү. Гади, тезмә һәм кушма фигыль хәбәрләрне дөрес билгеләү күнекмәләре булдыру.

**Тема 5. Иярчен кисәкләр. Иярчен кисәкләрне өйрәнү тарихы.Аергыч. Тәмамлык, аның төрләре. Хәл, аның төрләре. Аныклагыч. Модаль кисәкләр.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Иярчен кисәкләр. Иярчен кисәкләрне өйрәнү тарихы. Ачыклаулы мөнәсәбәткә кергән сүзләрнең иярүчесе буларак аергыч, тәмамлык, хәл. Аларның сөйләм оештыруда икече дәрәҗәдәге рольне уйнаулары. Аергыч, аның төп билгеләре. аергычның белдерелүе, аерылмышка бәйләнү юллары. Тәмамлык, аның төрләре. Туры тәмамлыкның мәгънәсе, бирелеше, иярткүче кисәккә бәйләнү юллары. Кыек тәмамлыкның мәгънәсе, бирелеше, иярткүче кисәккә бәйләнү юллары. Хәл, аның төрләре: вакыт, урын, сәбәп, максат, шарт, кире, рәвеш, күләм-чама хәлләре. Аларның бирелеше һәм иярткүче кисәккә бәйләнү юллары. Аныклагыч. ярашкан һәм ярашмаган аныклагычлар. Аныклагычлар янында тыныш билгеләре. Модаль кисәкләр, аларның сөйләмдәге роле.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Җөмләдән иярчен кисәкләрне аерырга өйрәнү. Аергычның үзенчәлекләрен, аерылмышка бәйләнү чараларын дөрес билгеләү. Тәмамлыкның туры һәм кыек төрләрен аерырга өйрәнү, аларның иярткүче кисәккә бәйләнү чараларын таба белү. Хәлнең үзенчәлекләре, вакыт, урын, сәбәп, максат, шарт, кире, рәвеш һәм күләм-чама хәлләрен таба белү күнекмәләрен булдыру. Иярчен кисәкләрне билгеләүдәге кыен очраклар. Аныклагычларны һәм модаль кисәкләрне дөрес билгеләргә өйрәнү.

**Тема 6. Тиңдәш кисәкләр. Җөмләнең синтагмаларга бүленеше. Аерымланган кисәкләр. Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше. Сүз тәртибе. Өстәлмәләр.**

***лекционное занятие (1 часа(ов)):***

Тиңдәш кисәкләр. Җөмлә кисәкләренең тиңдәшләнеп килүе өчен төп шарт - ияртүле бәйләнешнең булуы. Тиңдәш кисәкләрне үзара теркәүче чаралар. Тиңдәш һәм тиңдәш булмаган аергычлар. Тиңдәш кисәкләр янында гомумиләштерүче сүзләр. Тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләре. Җөмләнең синтагмаларга бүленеше. Аерым синтагма төзи һәм аерым синтагма төземи торган җөмлә кисәкләре. Аерымланган җөмлә кисәкләре, алар янында тыныш билгеләре. Җөмләнең актуалҗ кисәкләргә бүленеше: тема һәм рема. Аларның чылбырлы бәйләнеш хасил итүләре. Сүз тәртибе: уңай һәм инверсия. Өстәлмәләр һәм күзаллаулы баш килешле әйләнмә. Төрле җөмлә кисәкләренең өстәлмә булып килә алулары.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Тиңдәш кисәкләрне таба белергә өйрәнү. Тиңдәш һәм тиңдәш түгел аергычларның үзенчәлекләрен билгели белү. Төрле җөмлә кисәкләренең тиңдәшләнеп килә алуларына мисаллар туплау. Тиңдәш кисәкләр һәм гомумиләштерүче сүзләр янында тыныш билгеләрен куярга өйрәнү күнекмәләрен булдыру. Аерымланган кисәкләрнең астына дөрес итеп сызу. Тема белән ремане аерырга өйрәнү. Өстәлмәләрне һәм күзаллаулы баш килешле әйләнмәне башка берәмлекләрдән аерырга өйрәнү.

**Тема 7. Җөмлә төрләре. Раслау Һәм инкяр җөмләләр. Хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр. Тулы һәм ким җөмләләр. Җыйнак Һәм җәенке җөмләләр. Ике һәм бер составлы җөмләләр.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***

Җөмлә төрләре. Раслау һәм инкарь җөмләләр, аларның төп үзенчәлекләре. Инкарьны һәм раслауны белдерә торган чаралар. Инкарьны белдерүдә логик басым. Хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр. Аларның төп мәгънәләре һәм билгеләре. Сорау җөмлә төзелешендә татар теленең рус теленнән аермасы. Сорала торган кисәкнең урыны, аның логик басымны алуы. Бу җөмләдән соң тыныш билгеләре. Тулы һәм ким җөмләләр. Тулы җөмләнең үзенчәлекләре, ким җөмләнең үзенчәлекләре, кимлекнең сәбәпләре. Ким җөмләләрне өйрәнү тарихы. Ким җөмләләрне кимлек төренә карап төркемләү. Ким җөмләләрнең кулланылышы. Җыйнак һәм җәенке җөмләләр, аларның үзенчәлекләре. Таркалмый торган җөмләләр. Аларның бер төре буларак сүз җөмләләр. Ике һәм бер составлы җөмләләр. Бер составлы фигыль, исем һәм сүз җөмләләр. Билгеле үтәүчеле, билгесез үтәүчеле, гомум үтәүчеле һәм үтәүчесез бер составлы фигыль җөмләләр.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Тексттан раслау, инкаарь, җәенке, җыйнак, хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләрне аерырга өйрәнү. аларның кулланылыш үзенчәлекләрен билгеләү. Инкарь җөмләнең раслауны белдерә башлау очраклары. Сорау, боеру һәм тойгылы җөмләләрнең күрсәткечләрен билгеләү. Ике һәм бер составлы җөмләләрне аерырга өйрәнү.

**Тема 8. Кушма җөмлә. Тезмә кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә үзенчәлекләре.**

***лекционное занятие (1 часа(ов)):***

Кушма җөмлә. Тезмә кушма җөмлә төрләрен аеру. Иярченле кушма җөмлә. иярченле кушма җөмлә үзенчәлекләре. Иярчен җөмләләрне билгеләү һәм бу турыдагы карашлар. Иярченле кушма җөмләләрне төзелешеннән чыгып төркемләү: синтетик иярченле кушма җөмлә һәм аналитик иярченле кушма җөмләләр. Аларның төп үзенчәлекләре: бәйләүче чараларның иярчен җөмләдәге хәбәр составында тору-тормавы, иярчен җөмләнең чагыштырмача тәмамланган төсмер алу-алмавы, бәйләүче чараның компонентлар чиген билгеләү өчен нигез була алу-алмавы, компонентларның урынына бәйле үзенчәлекләр, иярчен җөмләдәге баш кисәкләрнең ярашу-ярашмавы, башка телләрдәге төзелешкә охшау-охшамау һ.б. Иярчен җөмләләрне мәгънә ягыннан төркемләү.

***практическое занятие (1 часа(ов)):***

Тексттан тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрне аерырга өйрәнү. Аналитик һәм синтетик иярченле кушма җөмләләрнең үзенчәлекләрен билгеләү. Иярченле кушма җөмләгә дөрес итеп синтаксик анализ ясарга өйрәнү, схемасын сызу үзенчәлекләре белән танышу.

**Тема 9. Иярчен җөмләләрнең төзелеш һәм мәгънә ягыннан төрләре. аларның синонимлыгы.**

***лекционное занятие (4 часа(ов)):***

Иярчен җөмлә төрләре. Иярчен ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, вакыт, урын, сәбәп, максат, шарт, кире, рәвеш, күләм, аныклагыч, кереш һәм өстәлмә җөмләләр. Аларның аналитик һәм синтетик төрләре. Җөмләләрне бер төрдән икенче төргә үзгәртү юллары.

***практическое занятие (4 часа(ов)):***

Иярчен җөмләләргә мисаллар эшләү. Аларның аналитик һәм синтетик төрләрен аерырга өйрәнү. Аларның синонимлыгына игътибар итү.

**Тема 10. Катлаулы кушма җөмлә төрләре: күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә, катнаш кушма җөмлә.**

***лекционное занятие (4 часа(ов)):***

Катлаулы кушма җөмлә, аның төрләре. Күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә. Катлаулы төзелмәләрнең үзенчәлеге, төрләре. Күп тезмәле катлаулы кушма җөмләләрнең компонентлары арасында бәйләнеш. Күп тезмәле катлаулы кушма җөмләләрнең схемасын төзү. Күп иярченле катлаулы кушма җөмләнең төрләре: тиңдәш иярүле, тиңдәш түгел иярүле, бер-бер артлы иярүле, берничә төр иярүле. Катнаш кушма җөмлә.

***практическое занятие (4 часа(ов)):***

Күп тезмәле катлаулы кушма җөмләне башка шундый берәмлекләрдән аерыу, дөрес итеп анализ ясау, схема сызу. Сөйләмдә күп тезмәле кутлаулы кушма җөмләләрдән файдалану. Күп иярченле катлаулы кушма җөмләгә һәм катнаш кушма җөмләгә анализ ясарга өйрәнү.

**Тема 11. Текст. Пунктуация.**

***лекционное занятие (4 часа(ов)):***

Текст. Тезем. Пунктуация. Тыныш билгеләрен төркемләү. Тыныш билгеләре һәм интонация. Аларның мәгънә белдерүдәге рольләре. Пунктуацион кагыйдәләр. Гади һәм кушма җөмләләрдә тыныш билгеләре. Тыныш билгеләре куелмый торган очраклар.

***практическое занятие (4 часа(ов)):***

Текстка анализ ясау. Тестта тиешле тыныш билгеләрен куярга өйрәнү. Куелган тыныш билгеләрен аңлату күнекмәләре булдыру.

### 4.3 Структура и содержание самостоятельной работы дисциплины (модуля)

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 2. | Тема 2. Җөмләгә билгеләмә. Җөмләнең төп үзенчәлекләре хәбәрлек һәм модальлек. Аларныӊ белдерелүе. Җөмләләрне төркемләү принциплары. | 8 | 2 | контрольная работа | 16 | письменная работа |
| 4. | Тема 4. Җөмләнең баш кисәкләре. Баш кисәкләрнең хәбәрлек оештырулары. Ия. Аның төп билгеләре. Хәбәр. Исем хәбәрләр. Фигыль хәбәрләр. Гади һәм тезмә фигыль хәбәрләр. Кушма фигыль хәбәрәр. | 8 | 4 | контрольная работа | 15 | письменная работа |

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | Тема 7. Җөмлә төрләре. Раслау һәм инкяр җөмләләр. Хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр. Тулы һәм ким җөмләләр. Җыйнак Һәм җәенке җөмләләр. Ике һәм бер составлы җөмләләр. | 8 | 7 | тест | 15 | письменная работа |
| 9. | Тема 9. Иярчен җөмләләрнең төзелеш һәм мәгънә ягыннан төрләре. аларның синонимлыгы. | 9 | 1 | тест | 1 | письменная работа |
| 10. | Тема 10. Катлаулы кушма җөмлә төрләре: күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә, катнаш кушма җөмлә. | 9 | 2 | контрольная работа | 1 | письменная работа |
| 11. | Тема 11. Текст. Пунктуация. | 9 | 3 | реферат | 1 | письменная работа |
| | Итого | | | | 49 | |

**5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения**

Вузовское освоение курса "Синтаксис современного татарского языка" предполагает использование как традиционных, так и инновационных образовательных технологий и требует рационального их сочетания.

Традиционные образовательные технологии подразумевают использование в учебном процессе таких методов работ, как лекция, практическое занятие, семинар и др.

Во время занятий могут быть использованы и современные информационные технологии, в частности, мультимедийные программы, Интернет, фото-, аудио- и видеоматериалы.

**6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов**

**Тема 1. Сөйләм төзелеше закончалыкларын өйрәнүче фән буларак синтаксис. Синтаксик берәмлекләр: сүзтезмә, җөмлә кисәге, җөмлә һәм текст. Интонация.**

**Тема 2. Җөмләгә билгеләмә. Җөмләнең төп үзенчәлекләре хәбәрлек һәм модальлек. Аларнњ белдерелүе. Җөмләләрне төркемләү принциплары.**

письменная работа , примерные вопросы:

Тексттан сүзтезмәләрне аерып чыгару һәм аларга анализ ясау.

**Тема 3. Сүзләрнең синтаксик бәйләнеше. Сөйләмне оештыручы төп бәйленеш буларак ияртүле бәйленеш. Сүзтезмә.**


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

**Тема 4. Җөмләнең баш кисәкләре. Баш кисәкләрнең хәбәрлек оештырулары. Ия. Аның төп билгеләре. Хәбәр. Исем хәбәрләр. Фигыль хәбәрләр. Гади һәм тезмә фигыль хәбәрләр. Кушма фигыль хәбәрәр.**

письменная работа , примерные вопросы:

Җөмлә кисәкләре ягыннан анализ ясау күнекмәләре булдыру.

**Тема 5. Иярчен кисәкләр. Иярчен кисәкләрне өйрәнү тарихы.Аергыч. Тәмамлык, аның төрләре. Хәл, аның төрләре. Аныклагыч. Модаль кисәкләр.**

**Тема 6. Тиңдәш кисәкләр. Җөмләнең синтагмаларга бүленеше. Аерымланган кисәкләр. Җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше. Сүз тәртибе. Өстәлмәләр.**

**Тема 7. Җөмлә төрләре. Раслау Һәм инкяр җөмләләр. Хикәя, сорау, боеру, тойгылы җөмләләр. Тулы һәм ким җөмләләр. Җыйнак Һәм җәенке җөмләләр. Ике һәм бер составлы җөмләләр.**

письменная работа , примерные вопросы:

Җөмлә кисәкләре һәм җөмлә төрләре белән бәйле тест эшләү.

**Тема 8. Кушма җөмлә. Тезмә кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә, аның төрләре. Иярченле кушма җөмлә үзенчәлекләре.**

**Тема 9. Иярчен җөмләләрнең төзелеш һәм мәгънә ягыннан төрләре. аларның синонимлыгы.**

письменная работа , примерные вопросы:

Гади һәм кушма җөмлә темасын кабатлаттыру максатыннан тест эшләү.

**Тема 10. Катлаулы кушма җөмлә төрләре: күп тезмәле катлаулы кушма җөмлә, күп иярченле катлаулы кушма җөмлә, катнаш кушма җөмлә.**

письменная работа , примерные вопросы:

Катлаулы кушма җөмлә темасына караган контроль эш эшләү.

**Тема 11. Текст. Пунктуация.**

письменная работа , примерные вопросы:

Тыныш билгеләре нигә кирәк? М.З.Зәкиевның хезмәтләренә күзәтү ясау. Яшҗ синтаксистлар һәм аларның хезмәтләре. Г.Ибраһимовның татар теле синтаксисына керткән өлеше. Г.Алпаровның хезмәтләренә күзәтү.

**Итоговая форма контроля**

экзамен (в 9 семестре)

Примерные вопросы к экзамену:

Рекомендации по выполнению плана самостоятельной работы

Особенностью дисциплины "Синтаксис современного татарского языка" является самостоятельная работа студентов, связанная с изучением проблемных вопросов по некоторым темам лекций.

Проверка выполнения плана самостоятельной работы проводится на практических занятиях.

Самостоятельная работа студентов по курсу призвана не только закреплять и углублять знания, полученные на аудиторных занятиях, но и способствовать развитию у студентов творческих навыков, инициативы, умению организовать свое время и выразить свою точку зрения на изученные проблемные вопросы.

При выполнении плана самостоятельной работы студенту необходимо прочитать теоретический материал не только в учебниках и учебных пособиях, указанных в библиографических списках, но и познакомиться с публикациями в периодических изданиях.

Студенту необходимо творчески переработать изученный самостоятельно материал и представить его для отчета в форме реферата, эссе и др.

Темы рефератов

1. Семантический (номинативный) синтаксис.

2. Актуальный синтаксис.

3. Конструктивный синтаксис.


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

4. Средства подчинительной связи.
5. Именные словосочетания
6. Глагольные словосочетания.
7. Грамматические схемы и модели простого предложения.
8. Предикативность предложения.
9. Модальность предложения
10. Порядок слов в в прозаической письменной речи.
11. Синтагматическое членение предложения.
12. Сложноспаянные предложения
13. Сложноподчиненные предложения.
14. Многочленные сложные предложения.
15. Синтаксис текста.

Контрольные вопросы и задания для проведения текущего контроля и промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины

Тесты (с элементами задания) для проведения контрольной работы

Гади җөмлә

1. Бер составлы фигыль җөмләгә карамаган төрне күрсәтегез:
а) билгеле үтәүчеле
б) үтәүчесез
в) номинатив
г) гомуми үтәүчеле
д) билгесез үтәүчеле
2. Кыек тәмамлык булган җөмләне билгеләгез, тиешле кисәкнең астына сызыгыз:
а) Баһау шүрли төште, ләкин ул моны сиздермәс өчен елмайган булды. (Г.М.)
б) Чөнки Татарстан халкы өчен бу бик кадерле һәм истәлекле газиз көн.
в) Дөньяның серен аңлар өчен, чәчәк серен белергә кирәк. (Р.Б.)
г) Әтием дә, аны озатыр өчен, ашыгып торып басты. (Р.Б.)
3. Кушма фигыль хәбәрле җөмләне табыгыз, хәбәрнең астына сызыгыз:
а) Мин сезгә ул турыда сүз бирәм.
б) Иртә белән көн томанлы иде.
в) Ике хәзрәт, ни өчендер, извозчик ялламакчы булалар.
г) Әптелбәр, уйнарга теләсә дә, бу тәкъдимне кире какты.
4. Җөмләнең хәбәрен табыгыз: Җиңелгәнне җиңел кичерә белгән кешеләр сирәктер дөньяда (М.Галиев)
а) кичерә белгән
б) сирәктер
в) дөньяда
г) хәбәре кулланылмаган
5. Җөмләнең иясен табыгыз: Дускай, сиңа бүләк итәр идем Илкәемнең иркә гөлләрен (М.Җәлил)
а) дускай
б) иясе кулланылмаган
в) сиңа
г) гөлләрен
6. Хәбәрнең астына сызыгыз һәм структур төрен билгеләгез: Хәлим аның сөйләгән сүзләрен колагына җыеп торды (И.Гази)
а) гади фигыль хәбәр
б) тезмә фигыль хәбәр


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

в) кушма фигыль хәбәр

7. Бер составлы фигыль җөмләнең төрен билгеләгез, хәбәрнең астына сызыгыз: Сүзне алардан башларга кирәк булгандыр миңа (Р.Төхвәтуллин)

а) билгеле үтәүчеле

б) билгесез үтәүчеле

в) гомуми үтәүчеле

г) үтәүчесез

8. Тезүле бәйләнешне белдерүдә катнашмаган чараны билгеләгез:

а) тезүче теркәгечләр

б) бәйлек һәм бәйлек сүзләр

в) санау интонациясе

г) каршы кую интонациясе

9.Ике составлы җөмләне табыгыз һәм баш кисәкләрнең астына сызыгыз::

а) Умырзая җыйдык, кошлар сайравын тыңладык, рәхәтләнеп ял иттек (Г, Мөхәммәтшин)

б) Аның күзләренә ак төшкән (М.Гафури)

в) Күңелемнең сине көткән чагы.

г) Аның бертуктаусыз каядыр йөгерәсе, чабасы килә, нидер эшлисе, кырасы-ватасы килә (Н.Фәттах)

10. Күләм хәле булган җөмләне билгеләгез, тиешле кисәкнең астына сызыгыз:

а) Айбиби бертын дәшми торды. (М.Х-н)

б) Малайлар учакны шәп итеп якканнар. (Г.Б.)

в) Тиен кинәт янәшә агачка сикерде . (Ә.Ф.)

г) Тузан суыргычтай йота Кала ыгы-зыгысы. (Л.Л.)

11. Сәбәп хәле булган җөмләне табыгыз, тиешле кисәкнең астына сызыгыз:.

а) Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп.

б) Таҗи шул уйлар белән чәй янынан торды.

в) Аның әрнүдән йокылары кача иде.

г) Без яшьтән үк таныштык.

12. Иярүче сүз ияртүчедән аңлашылган процессның максатын белдергән сүзтезмәне табыгыз:

а) талантка баш ию

б) урманга бару

в) суга чыгу

г) суыкка калтырау

13. Кушма фигыль хәбәрнең астына сызыгыз һәм белдергән мәгънәсен билгеләгез: Үкенечтән сыкрап куяр җаннар (Зөлфәт)

а) модаль мәгънәне

б) процессның үтәлү дәрәҗәсен

в) эзлекле процессны

г) заман мәгънәсен

14. Ачыклаулы мөнәсәбәтне табыгыз һәм бәйләүче чараны билгеләгез:

а) гүзәлсең син

б) Тукайның, бөек шагыйрьнең

в) Кара диңгез

г) урам буеннан йөрү

15. Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре (Г.Тукай) Хәбәрнең астына сызыгыз һәм структур төрен билгеләгез:

а) гади фигыль хәбәр

б) тезмә фигыль хәбәр

в) кушма фигыль хәбәр

г) тезмә исем хәбәр

16. Аерып бирелгән сүзләр нинди җөмлә кисәге булып килә: Сезнең кебек матур ярлар авылда ла түгел,илдә юк (Халык җыры)

а) аергыч

б) кыек тәмамлык

в) күләм хәле

г) рәвеш хәле

17. Ике составлы җөмләне табыгыз, баш кисәкләрнең астына сызыгыз:

а) Онытылып ук кителгән (Ф.Хөсни)

б) Беренче классы палубага беренче мәртәбә аяк басуыбыз (Р.Хәбибуллина)

в) Тимерне кызуында сугалар (М.)

г) Аяз иде ул көнне күк йөзе! (Г.Ахунов)

18. Аерып бирелгән сүз нинди җөмлә кисәге булып килә: Киткән урманга утынга, ялгызы бер ат җигеп (Г.Тукай)

а) туры тәмамлык

б) кыек тәмамлык

в) максат хәле

г) сәбәп хәле

18. Максат хәле булган җөмләне билгеләгез, тиешле кисәкнең астына сызыгыз:

а) Менә шунда үзе өчен бик кызыклы уен уйлап тапты. (Р.Н.)

б) Бу якты йорт сезнең бәхет өчен. (Ш.М.)

в) Кешегә мәшәкать ясаганым өчен уңайсызланып, тизрәк кайтырга җыендым.(Г.С.)

г) Бәлки, ул гомерендә беренче һәм соңгы тапкыр күченеп киткән өчен үкенгәндер. (Р.С.)

19. Җөмләнең баш кисәкләре арасында нинди мөнәсәбәт урнаша?

а) хәбәрлекле

б) ачыклаулы

в) аныклаулы

20. "Татар телендә сүз тәртибе" дигән хезмәтнең авторы кем?

а) М.М.Зәкиев

б) Ф.С.Сафиуллина

в) С.М.Ибраһимов

Кушма җөмлә

1. Компонентларның санына карап, кушма җөмләләр ике төргә бүленә:

1) ____________________________________________________________

2) ____________________________________________________________

2. Гомер узмый, Без узабыз, Шул гомер буйлап. (Р.Миңнуллин) Җөмләдәге сүтезмәләрне аерып алыгыз: ________________________________________________________

3 Компонентларының үзара нинди төр бәйләнештә торуына карап, кушма җөмләләр ике төрле була: 1) ____________________________________________________

2) ____________________________________________________

4. Баш килештәге исемнәрнең нинди җөмлә кисәге булып килүләрен асларына сызып билгеләгез: Җылы нурлары белән аны озата килгән, җемелдәшкән кар бөртекләре аша аның күзләренә өмет өстәп торган, гайрәт биргән кояш та алсуланып баерга җыена иде. (Р.Мөхәммәдиев)

5. Тезмә кушма җөмләләр, тезүле бәйләнешне тәгъбир иткән чарага карап, ике төрле була: 1) __________________________________________________

2) __________________________________________________

6. ) Теркәгечле тезмә кушма җөмләләрне үзара теркәү өчен хезмәт иткән тезүче теркәгечләрнең төрләрен билгеләгез һәм мисаллар языгыз:

1) ____________________________________________________________

2) ____________________________________________________________

3) ____________________________________________________________

7. ) Әни тамак кырды, әллә нәрсәләр миңа ымлады, мин көлә-көлә егеткә сөйли бирдем.(Г.Исхакый) Тезмә кушма җөмләдәге предикатив үзәкләрне, җөмлә чикләрен билгеләгез, бәйләүче чараны атагыз:_______________________________________________

8. Компонентлары үзара санау интонациясе аша теркәлгән ике компонентлы тезмә кушма җөмләгә мисал уйлап языгыз ______________________________________________

__________________________________________________________________________

9. да/дә теркәгечле тезмә кушма җөмләне табыгыз, компонентларының предикатив үзәкләрен һәм чикләрен билгеләгез:

1) Бүген көн аяз да, болытлы да. (Г.Т.)

2) Бүтән кызлар һәммәсе дә көянтә башларына берәр, икешәр каз элгәннәр, ә кунак кызның куллары буш. (Г.Б.)

3) Моны ул үзе дә белми, башкалар да сөйләмиләр. (Г.И.)

10. Ике компонентлы тезмә кушма җөмләдәге предикатив үзәкләрне, җөмлә чикләрен билгеләгез; һәр компонентка тиешле тәртиптә билгеләмә бирегез: Ә бит хан кызы үзе дә бик яхшы укый, иллә нигәдер һәрчак мөгаллименнән укытасы килә. (М.Хәбибуллин)

1 нче җөмлә -____________________________________________________________;

2 нче җөмлә -____________________________________________________________.

11. Тезмә кушма җөмләнең, составындагы компонентлар санына карап, төрен билгелә; һәр предикатив үзәкне, җөмлә өлешләренең чикләрен күрсәт: Оча алмадым, ә менә күңелдә илаһи ашкыну - биеклеккә ашу рәхәте, хозурлыгы ымсындырып калды, мин аны татлы серем итеп күңелдә кичерәм. (Ш.Галиев) _________________________________

12. Тезмә кушма җөмләдәге предикатив үзәкләрне билгеләгез, җөмләләрнең чикләрен күрсәтегез, тыныш билгеләре куелу кагыйдәләрен языгыз: Бүтән кызлар һәммәсе дә көянтә башларына берәр, икешәр каз элгәннәр, ә кунак кызының куллары буш. (Г.Бәширов)

____________________________________________________________________

13. Ул ил өстенә төшкән кайгыны - сугыш чорын күз алдына китерде. (Г.Зәйнәшева) Җөмләдә сызык куелу кагыйдәсен языгыз: ____________________________

14. Тән зиннәте кием акыл зиннәте гыйлем. (М.) Җөмләдә тыныш билгеләрен куегыз, кагыйдәләрен языгыз: ____________________________________________________

15. Нәкъ шул вакыт күз ачыргысыз әче җил исте, ком бураны дөньяны томалады. (М.Хасанов) Җөмләнең предикатив үзәкләрен билгеләгез, өлешләренең чикләрен күрсәтегез, һәр ике төр схемасын сызыг:

16. Кушма җөмләне табыгыз, предикатив үзәкләрен, җөмлә чикләрен билгеләгез:

1) Хан сараен һәм хан мәчетен ике катлы таш диварлар белән әйләндереп алган дәһшәтле кирмән каршындагы иркен мәйдан халык белән шыгрым тулы иде.(В.Имамов)

2) Чит илләрдә күп йөрдем, Газиз башым гыйбрәт алсын дип . (Җыр)

3) Ул бераз торганнан соң өйгә керде, һәм, мендәренә капланып, әкрен генә үксеп-үксеп елый башлады. (Ш. Камал)

17. Җөмләдә тиешле тыныш билгеләрен куегыз: Укучылар казлар кебек тезелешеп бәрәңге алырга чыктылар бармады. (А.Гыйләҗев)

18. Тезмә кушма җөмләгә тулы синтаксик анализ ясагыз:

Идрис хәзрәтнең каракучкыл йөзе күл өстедәй тыныч, фәкать карашында гына нindидер шик, икеләнү газаплары пыскып яна иде. (В.Имамов)

Задания и тексты к контрольной работы

Тәкъдим ителгән җөмләләргә тулы синтаксик анализ ясагыз.

1) Күреп торасыз: фуражы бар хуҗалыклар салам юктан интегә. (Х.Х.)

2) Без торганда, Гөлбикәнең самавыры кайнаган, коймагы пешкән иде. (Г.Ибраһимов)

3) Очрашу гаять шатлыклы булды: күпләр сөенечтән көләләр, ә кайберәүләр елыйлар иде. (Р.М.)

4) Бу урында шуны әйтим әле: ул килер алдыннан, мин бер нәрсә турында баш ваттым. (Ә.Е.)

5) Тагын шуны онытма: син антыңны бозсаң, бөтенебезне дә һәлак итәсең. (М.Нас.)

6) Кешеләр, көлешә-көлешә, каядыр ашыгалар, кемнәрдер каршы алалар, кемнәрдер озаталар. (Г.Ә.)

7) Мин дә киткәч, син дә киткәч, монда кем соң эшләр? (С.К.)

8) Сәет Вахиди йөреп чыккан авылларның, ул шакыган ишекләрнең санын әле беркем дә белми. (М.Г.)

9) Кыш көне утын булмаганлыктан, салам ягалар иде. (М.Г.)

10) Халык ятып, мәдрәсә тынгач кына, Габделбасыйр бу хатны Әхмәткә күрсәтте. (Ф.Ә.)

11) Уйнадың да очып китең

Күз күрмәгән якларга. (Э.Ш.)

12) Минем абый атларны борган арада, юл әйберләре онытылып калмасын дип, мин өйгә тагын бер тапкыр кереп чыктым. (М.Ә.)

13) Кемнең икмәге мул, кемнең халкы бер җан, бер тәндәй оешкан, шул җиңеп чыга. (Г.Б.)

14) Без авылдан чыкканда, көн матур, җил юк иде. (Г.И.)

15) Яралары төзәлеп беткәнче дип, хәрби госпитальдән аны берничә айга авылга кайтарганнар. (А.Ш.)

16) Гөлбануның кул тамырларында куәт кайнады, нәкъ ире Закир чәнечкәнчә, дүрт-биш кибәнне, җирдән эшереп китереп, бергә өйде дә, тимер сәнәкне батырып җибәрде, чүмәлә зурлыгы күтәреп алып, арбага бәйләнгән аркылы чыбыклар өстенә китереп салды. (Г.И.)

17) Мин өнсез идем, мин бер сүз дәшәргә җөрьәт итмәдем, һәм кирәкми дә иде ул. (Ә.Е.)

18) Гөлбану бу мактаудан күңеллеләнде, үзенә сокланып карап, көзге алдында әйләнде, күзенә, битенә елмаю чыкты, шуның белән баягы елау эзе бөтенләй югалып ук китте. (Г.И.)

19) Күңеле кинәт ташу сәбәпле, кыз берни дә әйтә алмады. (Г.Ә.)

20) Урсал тайны сары сарган, Әллә шуңа кайгырам. (С.С.)

Вопросы к экзамену прилагаются в виде Приложения �1 (с.16-18)

**7.1. Основная литература:**

1. Скобликова, Е. С. Современный русский язык. Синтаксис простого предложения (теоретический курс) [Электронный ресурс]: учеб.пособие / Е. С. Скобликова. - 4-е изд., стер. - М.: Флинта, 2012. - 320 с. http://znanium.com/bookread.php?book=490395

2. Федосюк М. Ю. Синтаксис современного русского языка [Электронный ресурс]: Учебное пособие / М.Ю. Федосюк. - М.: НИЦ Инфра-М, 2012. - 245 с. - Режим доступа: // http://znanium.com/bookread.php?book=303968

3. Вараксин Л. А. Современный русский язык. Синтаксис простого предложения: Сборник упражнений [Электронный ресурс] / Л.А. Вараксин. - М.: Флинта: Наука, 2010. - 208 с. - Режим доступа: // http://znanium.com/bookread.php?book=241679

4. Рогачева, Е. Н. Русский язык: синтаксис и пунктуация. Второй уровень владения языком [Электронный ресурс] : учеб.пособие / Е. Н. Рогачева, О. А. Фролова, Е. А. Лазуткина. ? М.: ФЛИНТА, 2013. ? 117 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=462965

5. Павлов, А. В. Методологические проблемы современного гуманитарного познания [Электронный ресурс]: учеб. пособие / А. В. Павлов. - М.: ФЛИНТА, 2013. - 325 с. http://www.znanium.com/bookread.php?book=466244

**7.2. Дополнительная литература:**


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

1. Константинова Л. А. Грамматика русского языка [Электронный ресурс]: Учеб.пособие / Л.А. Константинова, Н.Н. Гончарова, А.Н. Жукова; Под ред. Л.А. Константиновой. - М.: Флинта: Наука, 2011. - 256 с. - Режим доступа: // http://znanium.com/bookread.php?book=304030

2. Соловьёва Н.Н. Полный справочник по русскому языку: Орфография. Пунктуация. Орфоэпия. Лексика. Грамматика. Стилистика [Электронный ресурс]. - Москва: ООО 'Издательство Оникс': 'Издательство 'Мир и образование': 'Издательство Астрель', 2011. - 464 с. - Режим доступа: // http://www.bibliorossica.com/book.html?currBookId=3486

3. Киселев, Г. М. Информационные технологии в педагогическом образовании [Электронный ресурс] : Учебник для бакалавров / Г. М. Киселев. - М.: Дашков и К, 2013. - 308 с. // http://znanium.com/bookread.php?book=415216

4. Информационно-предметное обеспечение учебных дисциплин бакалавриата и магистратуры: Учеб.-метод. пособие / Н.А.Логинова - М.: НИЦ ИНФРА-М, 2014. - 124 с. http://znanium.com/bookread2.php?book=460217

### 7.3. Интернет-ресурсы:

www.gramota.ru - Грамота.ру

www.gumer.info - Библиотека Гумер - гуманитарные науки

www.rsu.ru - Электронная библиотека и материалы сайта КПФУ

www.slovari.ru - Электронные словари

www.wikipedia.ru - Универсальная энциклопедия

### 8. Материально-техническое обеспечение дисциплины(модуля)

Освоение дисциплины "Современный татарский язык: Синтаксис (в татарском языке)" предполагает использование следующего материально-технического обеспечения:

Компьютерный класс, представляющий собой рабочее место преподавателя и не менее 15 рабочих мест студентов, включающих компьютерный стол, стул, персональный компьютер, лицензионное программное обеспечение. Каждый компьютер имеет широкополосный доступ в сеть Интернет. Все компьютеры подключены к корпоративной компьютерной сети КФУ и находятся в едином домене.

Для проведения занятий по "Синтаксису современного татарского языка" необходимы учебная и учебно-методическая литература, сборники текстов произведений татарских писателей и поэтов, а также демонстрационные материалы.

Необходимы следующие технические средства:

1. Мультимедийный компьютер с выходом в Интернет, с пакетом прикладных программ (текстовых, графических, презентационных).
2. Мультимедиапроектор.
3. Сканер.
4. Принтер.
5. Копировальный аппарат.
6. Ноутбук.

Программа составлена в соответствии с требованиями ФГОС ВПО и учебным планом по направлению 44.03.05 "Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)" и профилю подготовки Родной (татарский) язык и литература и иностранный язык (английский) .



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Автор(ы):
Мирзагитов Р.Х. ____________________
Сагдиева Р.К. ____________________
"__" _________ 201 __ г.

Рецензент(ы):
"__" _________ 201 __ г.